Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

30.01.2024 Менделеевск ш. №46

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районында
жирләү буенча хезмәтләрнең
гарантияләнгән исемлеге нигезендә
күрсәтелә торган хезмәтләрнең
бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында 8370 сум 20 тиен күләмендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырырга.

3. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварендагы 49 номерлы карары 2024 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары С.В. Метальниковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 30 гыйнварындагы 46 номерлы
карарына 1 кушымта

2024 елның 1 февраленнән
Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында
җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2819,72 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 1192,88 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4357,60 |
| Барлыгы | 8370,20 |

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 30 гыйнварындагы 46 номерлы
карарына 2 кушымта

2024 елның 1 февраленнән
Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында
җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 146,96 |
| 3. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2672,76 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 1192,88 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4357,60 |
| Барлыгы | 8370,20 |